РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » 11 2023 г. №1919

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында" 2019 елның 12 декабрендәге 970-ИК номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының вәкаләтләрен киңәйтү, шулай ук аларны "Административ хокук бозулар турында” Татарстан Республикасы кодексына һәм "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 21.07.2023 № 67-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы таләпләренә туры китерү максатларында, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Кушымтаны түбәндәге эчтәлектәге бүлек белән тулыландырырга:

| Административ хокук бозулар турында ТР Кодексы статьялары | Статьяның эчтәлеге | Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары |
|---|---|---|
| Административ хокук бозулар турында ТР Кодексының 2.21 ст. | Режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Татарстан Республикасы | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы |

| | | |
|---|---|---|
| | норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П.Самонина

З.М. Латыйпова
(85593) 2-42-05